| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

## 2020 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында

Театр, музыка, хореография сәнгате һәм кинематография өлкәсендә әйдәп баручы коллективларның аеруча әһәмиятле иҗади проектларына дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының $28^2$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын гамәлгә кую турында» 2007 елның 2 апрелендәге ПУ-168 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2020 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын алучылар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры;

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры;

Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле;

Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры;

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе;

В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры;

Татарстан Республикасы «Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

«Бөрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле.

2. 2020 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын түләүгә акчаның гомуми күләмен 339 358,4 мең сум итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү буенча чаралар күрергә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 06 март
№ ПУ-153